# 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Лабышка Тәмте авылында үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

2022 елның 28 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Лабышка Тәмте авыл җирлегендә гражданнар җыены карар итте:

1.2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Лабышка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- бистә эчендәге һәм йөри торган юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (вак таш сатып алу, таш салу, грейдирование, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

-җәйге-көзге чорда чүп үләннәрен чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

-юлларны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- урамнарны яктырту (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Лабышка авылы, Тукай урамы (кибет бинасы); шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Тәмте авыл җирлеге башлыгы

Кама Тамагы муниципаль районы

Татарстан Республикасы районнары: И. А. Зиновьев